КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 июнь г.Казань № 481

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлары-ның, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 апрель, 281 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның беренче абзацында «муниципаль берәмлекләр (шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең дүртенче – җиденче, тугызынчы – уникенче төркемнәренә кертелгән муниципаль берәмлекләрдән башка)» сүзләрен «шәһәр округлары һәм муниципаль районнар булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең беренче – дүртенче һәм сигезенче төркемнәренә кертелгән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$. Шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең дүртенче – җиденче, тугызынчы – уникенче төркемнәренә кертелгән муниципаль берәмлекләр башлыкларына айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, муниципаль хокукый актлар нигезендә айлык акчалата бүләкләү, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә акча, премияләр түләнергә мөмкин.»;

7 пунктның беренче абзацында «муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына (шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең дүртенче – җиденче, тугызынчы – уникенче төркемнәренә кертелгән муниципаль берәмлекләрдән башка)» сүзләрен «шәһәр округлары һәм муниципаль районнар булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең беренче – дүртенче һәм сигезенче төркемнәренә кертелгән»;

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$. Шәһәр һәм авыл җирлекләре булып торган һәм хезмәт өчен түләүнең дүртенче – җиденче, тугызынчы – уникенче төркемнәренә кертелгән муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, муниципаль хокукый актлар нигезендә айлык акчалата бүләкләү, тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә акча, премияләр түләнергә мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин